КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 март г.Казань № 131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел,

24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август, 762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 15 июль, 677 нче; 2022 ел, 4 август, 757 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1202 нче; 2023 ел, 3 март, 201 нче; 2023 ел, 1 июнь, 669 нчы; 2023 ел, 3 июль, 773 нче; 2023 ел, 11 июль, 811 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы; 2023 ел, 28 сентябрь, 1193 нче; 2024 ел, 29 гыйнвар, 40 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

20.1 пунктның 2 графасында «булдыру» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

20.108 пунктның 2 графасында «(ылыслы агачлар төрләре)» сүзләрен «ылыслы агачлар төрләренең (нарат, чыршы, карагай)» сүзләренә алмаштырырга;

20.109 пунктның 2 графасында «утыртмалары» сүзләре алдына «яфраклы агачлар төрләре» сүзләрен өстәргә;

20.110 пунктның 2 графасында «(яфраклы агачлар төрләре)» сүзләрен «яфраклы агачлар төрләре (каен)» сүзләренә алмаштырырга;

20 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 20.145 – 20.150 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «20.145. | Урман орлыкчылыгы объектларында, шулай ук ылыслы агачлар төрләренең (Себер кедр нараты, Корея кедр нараты) иң яхшы һәм нормаль утыртмаларында урман үсемлекләре орлыкларын хәзерләү | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | орлык саны, килограмм | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы ($50^7$, 61, 64, 82, 83 статьялар); 2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы |
| 20.146. | Урман орлыкчылыгы объектларында, шулай ук башка яфраклы агачлар төрләренең иң яхшы һәм нормаль | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | орлык саны, килограмм | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы ($50^7$, 61, 64, 82, 83 статьялар); 2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | утыртмаларында урман үсемлекләре орлыкларын хәзерләү | | | | | | | | | | | | | | | | органнарына тапшырылган урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы |
| 20.147. | Урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү ихтыяҗлары өчен урман питомникларында төп урман агач төрләренең ябык тамыр системалы үсентеләрен үстерү | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | үстерелгән үсентеләр саны, данә | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы ($50^7$, 61, 64, 82, 83 статьялар); 2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20.148. | Урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү ихтыяҗлары өчен урман питомникларында төп урман агач төрләренең ачык тамыр системалы үсентеләрен үстерү | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | үстерелгән үсентеләр саны, данә | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы (50$^7$, 61, 64, 82, 83 статьялар);<br>2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы |
| 20.149. | Урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү ихтыяҗлары өчен урман питомникларында төп урман агач төрләренең ябык тамыр системалы | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | үстерелгән үсентеләр саны, данә | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы (50$^7$, 61, 64, 82, 83 статьялар);<br>2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган урман мө- |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чәчкеннәрен үстерү | | | | | | | | | | | | | | | | мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы |
| 20.150. | Урманнарны торгызу һәм урманнарны үрчетү ихтыяҗлары өчен урман питомникларында төп урман агач төрләренең ачык тамыр системалы чәчкеннәрен үстерү | | | | эш | дәүләт эше түләүсез | 02.40 | 01.01.2024 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | җәмгыять мәнфәгатьләрендә | үстерелгән үсентеләр саны, данә | | юк | юк | 1) Россия Федерациясе Урман кодексы ($50^{7}$, 61, 64, 82, 83 статьялар); 2) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең кайбер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 6 августындагы 529 номерлы боерыгы. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин